# КАРАР

**“09” ноябрь 2021 ел** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Субаш-Аты авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, 2021 елның 09 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

««Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәрендәге сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен светодиодлы яктырткычлар сатып алу;
- торак пункт территориясендә һәм Аты елгасы буйлап агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару;
- зират янында чүп-чар җыю өчен материал сатып алу һәм металл контейнер ясау;
- вак таш сатып алу, җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл катламнарына таш җәю һәм тигезләү;
- амкадор, бульдозер хезмәтләре өчен түләү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ» “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 151 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 86 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 86 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар- Аты авыл җирлегендә Субаш-Аты авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2 ««Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәрендәге сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен светодиодлы яктырткычлар сатып алу;

- торак пункт территориясендә һәм Аты елгасы буйлап агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару;

- зират янында чүп-чар җыю өчен материал сатып алу һәм металл контейнер ясау;

- вак таш сатып алу, җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл катламнарына таш җәю һәм тигезләү;

- амкадор, бульдозер хезмәтләре өчен түләү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ» -86 “КАРШЫ“-0

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Субаш - Аты авылы, 9 Май урамы, 11 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Утар -Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева